КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 апрель г.Казань № 465

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклавы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 ел, 11 май, 431 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклавы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклавы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 ел, 11 май, 431 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклавы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III бүлекнең 2 пунктындагы таблицада:

30 пунктта «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Зур яшьтәге кешеләрнең билгеле бер төркемнәренә профилактик медицина тикшерүе һәм диспансеризация үткәрү тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 мартындагы 124н номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Зур яшьтәге кешеләрнең билгеле бер төркемнәренә профилактик медицина тикшерүе һәм диспансеризация үткәрү тәртибен раслау турында» 2021 елның 27 апрелендәге 404н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «34. | Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды-ның Татарстан Республикасы буенча бүлеге белән хезмәт-тәшлек итү буенча «Электрон бала тудыру сертификаты» сервисы | Система белән Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге арасында электрон мәгълүмат алмашу»; |

V бүлекнең 3 пунктындагы бишенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекнең 3 пунктындагы алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

VIII бүлекнең өченче абзацында «Россия Федерациясе Социаль иминият фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Республики Татарстан А.В.Песошин